СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2025 г. Агрыз № 47-7

## 2025 һәм 2026 елларда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 494-ФЗ номерлы федераль законнары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 һәм 2026 елларда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелми дип билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru).

1. 5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев